КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 588

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2019 ел, 29 март, 242 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2019 ел, 29 март, 242 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 гыйнвар, 59 нчы; 2020 ел, 15 июль, 596 нчы; 2021 ел, 15 гыйнвар, 10 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2019 – 2025 елларга» сүзләрен «2019 – 2023 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2019 – 2025 елларга» сүзләрен «2019 – 2023 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин